«РУБИН» – ЧЕМПИОН!

Казан футболчылары беренче лигада беренче урынны алды

> 3

АНГЕЛИНА ГАЛИМОВА:

«Безнең егетләр кем белән һәм нәрсә хакына көрәшкәнен яхшы аңлый»

> 3

МОҢЛЫ ЯРМИНКӘ

Лаеш районының Никольское авылында 31 нче тапкыр Каравон бәйрәме гөрләде

> 4

ӘСТЕРХАНДА ҖЫЕЛДЫК

Бөтенроссия авыл Сабан туенда илнең 30 төбәгеннән 50 меңнән артык кунак катнашты

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 75 (29042) | Сишәмбе | 30 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

СЫНАТМАСЫН ХӘТЕР!

РЕСПУБЛИКАДА БЕРДӘМ ДӘҮЛӘТ ИМТИХАННАРЫ БАШЛАНДЫ

Кичә 11 нче сыйныф укучылары быелгы беренче сынауны – рус теленнән БДИ тапшырды. Казанның 183 нче гимназиясендә оештырылган имтихан пунктына укучыларның хәлен белешергә Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да килгән иде.

«Татар-информ» / Михаил Захаров

Елмаялар, көлешәләр... Күңелләрендә борчу булса да, имтихан тапшырырга килүче егет-кызлар эчтәгесен күрсәтмәскә тырыша. Гимназия ишек төбендә үзенә күрә бер җылы мохит. Күбесе төнлә йоклый алмаган, шуңа да карамастан, кәефләре яхшы. Әти-әниләре өйдән тынычландырып җибәргән икән.

– Мине күтәренке кәеф белән имтиханга җибәрү өчен, әни ял алды. Тәмле ризыклар пешереп көтеп торачак. Өстәвенә абыемның туган көне. БДИны яхшы нәтиҗәләргә биреп, аны сөендерәсем килә, – ди Казандагы 125 нче мәктәп укучысы Рәсил Сөнгатуллин. – Атна буе көненә тугызар сәгать рус теленнән вебинарлар тыңладым, кагыйдәләрне искә төшердем. Ел дәвамында репетиторлар белән дә шөгыльләндем. Күпме акча түгелгәнен белмим, санамадым. Кичә көн буе ял иттем. Тик төнлә йокыга китә алмыйча боргаланып яттым. Бүтән чакта иртән мине танк белән дә уята алмыйлар иде, бүген бер әйтүгә сикереп тордым. Өйдә, борчылма, иң мөһиме: чик баллга бир, дип тынычландырдылар. КАИга программистлыкка укырга керергә җыенам. Миңа бары яхшы баллар гына кирәк.

Башкаладагы 169 нчы мәктәпне тәмамлаучы Гадел Хөсәеновның да хәле Рәсилнеке кебегрәк. Ул да төнлә йоклый алмаган.

– «Улым, нигә борчыласың соң син, әйдә, бергәләп тәмләп чәй эчәбез», – дип, әни табынга дәште. Аның белән сөйләшеп утырдык, аннан тынычландым. Кәефем яхшы. Менә хәзер керәбез, язабыз... Бөтенесе дә яхшы булачак, Алла боерса. Дулкынланмыйча булмый инде анысы. Рус теле, математика, биология сынауларын бирәм. Медицина вузына укырга керәсем килә, – ди егет. Гадел патриот та булып чыкты. Имтихан пунктына «Мин яратам сине, Татарстан», – дип җырлый-җырлый кереп китте ул.

Алиса Кремкова киләчәктә психолог булырга җыена. «Белем булса да, бераз куркыта инде. Үземне тынычландырдым. Әти-әниләр дә бик борчыла. БДИ кирәкми дип саныйм, ул – укучы өчен бик зур борчу», – ди Алиса. Укучылар арасында әле кая барасын хәл итмәгәннәре дә бар. «Башта имтихан бирик, аннан күз күрер. Имтихан баллы кая җитә, шунда керербез», – диючеләр дә булды.

Укытучылар да борчыла, әлбәттә. Ләйлә Жарова 169 нчы мәктәптә география укыта. Кадет сыйныфын җитәкләгән икән. Быел укучыларның дүртесе тикшерүче белгечлеген сайлаган. Арада булачак юристлар, табиблар, укытучылар, программистлар да бар.

– Балалар әзер, бары борчылмасыннар гына инде. Барысын да яратам. Ел саен традиция буенча 1 сентябрьдә хәлемне белергә киләләр. Ел дәвамында аралашып торабыз, – диде ул.

Кичә – укучы, бүген инде – җәмгыять күзәтүчесе. ТИСБИның 1 курс студенты Вилия Галиева имтихан барышын күзәтергә килгән. Аның әйтүенчә, әлегә барысы да тәртиптә.

Сан

Рус теле имтиханында **15062** укучы катнашкан. Шуларның **200**дән артыгы – сәламәтлеге чикләнгән балалар – сынауны башка формада бирде. Республикада **98** имтихан пункты эшли, шуның **83**е – мәктәпләрдә, калганы – өйдә. БДИда **5** меңләп укытучы катнаша.

– Балаларның металл кысадан кергәннәрен карыйбыз. Әгәр имтихан уздырылмый торган бүлмәләрнең ишеге ябыштырылмаса, бу кагыйдә бозу булып санала. Бәдрәфкә барганда, укучыны оештыручылар озатып барырга тиеш. Язып бетергәч, материалларның ничек кабул ителүен, гомумән, барысын да күзәтәбез. Кагыйдә бозу очраклары булганда, имтихан комиссиясенә җиткерәбез. Дүрт имтиханда катнашачакмын, – ди Вилия.

Балаларның имтиханга әзер икәнлеген министр үзе дә әйтте. Илсур Һадиуллин белдергәнчә, иң мөһиме – ут сүнмәсен, давыл чыкмасын... Тәрәзәне ачкач, җил материалларны бутап бетерсә дә, куркыныч. Шуңа күрә аны бик зур итеп ачарга да ярамый дип кисәтте.

– Имтиханнарга әзерлек еллар буе бара. Бөтен борчулар артта калырга тиеш. Шпаргалка, хәйләкәр юллар белән баллар алырга тырышмасыннар иде. Бәдрәфкә 6–7 тапкырдан да күбрәк чыгучылар контрольгә алыначак. Имтихан биремнәрен бүлмәдән алып чыгарга ярамый. Җәмәгать күзәтүчеләре күзәтә, федераль инспекторлар да бар. Шуңа күрә укучыларны кисәттек. Балаларның тырышлыгы, әзерлеге бик мөһим. Без дә алар өчен борчылабыз, – диде Илсур Һадиуллин. – Рус теленнән 27 бирем каралган. Укучы 24 балл җыйса, ул чикне үтте дигән сүз. Әлбәттә, күбесенең яхшы баллар туплап, югары уку йортларына керәсе килә. Барысын да уңышлы башкарып чыксак, безнең өчен зур бәйрәм булачак. Медалистларга рус теле һәм математикадан 70тән ким булмаган балл туплау таләбе куелган.

Рус теле сынавы нәтиҗәләре 16 июньдә билгеле булачак. Чик баллны җыя алмаучылар аны кабат йә 22 июнь яки 1 июльдә бирә ала. Математика сынавы исә 1 июньдә көтелә.

Эшне җиңеләйткәннәр

Россия Президенты Владимир Путин кайбер пенсияләрне гариза тапшырмыйча гына билгеләү турында законга кул куйган. Шулай итеп, әтисе дә, әнисе дә мәгълүм булмаган балалар, туендыручысын югалткан гаиләләр, халыкның кайбер башка категорияләре гаризасыз гына социаль һәм иминият пенсияләре ала башлаячак.

Законда күрсәтелгәнчә, түләү пенсия белән тәэмин итүгә җаваплы органның мәгълүматлары нигезендә билгеләнәчәк. Пенсия түләү турында карар 5 эш көне эчендә кабул ителәчәк. Иминият пенсиясенә дә, социаль пенсиягә дә хокуклы булучыларга кайсы отышлырак – шунысы билгеләнәчәк.

Моннан тыш «эшкә сәләтсез гражданнар» төшенчәсе аныкланган. Хәзер аңа 9 нчы яки 11 нче сыйныфны тәмамлаган балигъ булмаган үсмерләр (укуны тәмамлаган елның 1 сентябренә кадәр) кертелә.

Хастаханәләр яңартыла

Республикада 1 декабрьгә кадәр 6 медицина оешмасы бинасы капиталь төзекләндереләчәк. Бу эшкә республика бюджетыннан 508,9 миллион сум акча тотарга ниятлиләр.

«Реальное время» электрон басмасы хәбәр иткәнчә, Түбән Кама күппрофильле хастаханәсенең икенче дәвалау корпусын төзекләндерү барыннан да кыйммәткәрәк төшәчәк. Аның өчен 335 миллион сум каралган. Проект документлары буенча, бинада яңа җилләткеч, җылыту һәм канализация системалары булдырылачак, лифтлар, видеокүзәтү камералары, сигнализация урнаштырылачак. Моннан тыш кирәкле барлык мебель һәм җиһазлар сатып алыначак.

Төзекләндерелергә тиешле корылмалар исемлегенә Мамадыш район үзәк хастаханәсенең сырхауханәсе (16,1 миллион сум акча тотылачак), шушы ук хастаханәнең хирургия бүлеге (45,8 миллион сум), Буа медицина училищесы (9,1 миллион сум), Казан наркология диспансерының 1, 2 һәм 3 нче стационар бүлекләре (92,7 миллион сум), Яшел Үзәннең Психологик-педагогик ярдәм үзәге (10 миллион сум) бинаалары кергән.

«Татар-информ»

Яңалык

Паспортның кирәге калмый?!

Июньдә Татарстанда яшәүче картасы гамәлгә керер дип көтелә. Бу хакта Татарстанның цифрлы үсеш, дәүләт идарәсе, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин әйткән. Пластик карта ярдәмендә җәмәгать транспортында түләргә дә, табибка язылырга да мөмкин булачак.

– Бар да тәртиптә булса, 1 июнь... яки 12 июньдә Татарстанда яшәүче картасын чыгара башлаячакбыз, – дип сөйләгән министр ТАСС хәбәрчесенә.

Айрат Хәйруллин сүзләренә караганда, картаның эскизы әзер. Татарстанда яшәүче картасын алырга теләүчеләрдән тәүге гаризалар да кабул иткәннәр инде.

Исегезгә төшерәбез: әлеге карта «Мир» түләү системасы нигезендә эшләячәк. Әлеге проектны тормышка ашыру турындагы килешүне узган ел Төньяк башкалада узган «Петербург халыкара икътисадый форумы»нда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм түләү системасы генераль директоры Владимир Комлев имзалады. Владимир Комлев республиканы мәгълүмати технологияләр өлкәсендә алга киткән төбәк дип атады.

– Без Татарстанда гамәлдә булган цифрлы продуктларны саклап калып, аларны тагын да тулыландырачакбыз. Мәсәлән, яңа карта түләүләр белән беррәттән, республикада гамәлдә булган ташламаларны да колачлаячак, – диде ул форумда.

Татарстанда яшәүче картасы нәрсәдән гыйбарәт? Айрат Хәйруллин әйтүенчә, ул гадәти банк картасыннан аермалы буларак, хуҗасы турындагы бөтен мәгълүматны саклаячак. Мәсәлән, әлеге картага паспорт, полис, СНИЛС мәгълүматларын яздырачаклар. Шуңа күрә алга таба үзең белән кәгазь документлар йөртүнең кирәге калмаячак, дип фаразлана. Карта ярдәмендә табибка язылу да җиңеләячәк, диләр. Ак халат ияләренә дә эш кими. Карта аша авыруның электрон медицина картасын ачып карап булачак. Акчалы булгач, аны җәмәгать транспортында түләү өчен файдаланырга ярый. Моннан тыш, картага хезмәт хакы, пенсия, социаль түләүләр дә килә ала. Соңгысы турында мәгълүмат та алып булачак әле. Мәсәлән, яшь әниләр балага күпме пособие тиеш һәм аны ничек алып буласын белешергә мөмкин. Карта пластик та, виртуаль да булачак дип көтелә.

Татарстан өчен бу яңалык түгел. Хәтерләсәгез, 2016 елда республиканың Яшел Үзән районында тәҗрибә рәвешендә Татарстанда яшәүче картасы гамәлгә кергән иде. Аны банк һәм социаль яклау бүлекчәләрендә бушлай рәсмиләштерделәр. Татарстан Цифрлы үсеш, дәүләт идарәсе, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгы мәгълүматларына караганда, әлеге проект гамәлдә булган 2016–2019 елларда Яшел Үзәндә 40 меңнән артык кешегә Татарстанда яшәүче картасы бирелгән.

Фикер

Игорь АНИКИН, КНИТУ-КАИның Мәгълүмати куркынычсызлык системалары кафедрасы җитәкчесе:
– Техник яктан, мәгълүматны картада саклау куркынычсыз булып санала. Интернет аша аннан берни дә тартып чыгарып булмаячак. Әмма кеше факторы бар. Мондый карта хуҗалары шәхси мәгълүматны тиешенчә сакларга тиеш. Аны башкаларга бирмәскә, теге яки бу урында пин-код керткәндә, саннарны кул белән томаларга киңәш ителә.

(«АиФ» басмасына биргән әңгәмәсеннән)

Сүзгә-сүз

Илдус ЛОТФУЛЛИН, педиатр, медицина фәннәре кандидаты:

Эчкече яки наркоманнар гаиләсендәге балалар белән генә куркыныч очраклар килеп чыга дип уйлау – зур ялгышу. Мондый хәл теләсә кем белән булырга мөмкин. Җәй ул – күңел ачу гына түгел, имгәнү куркынычы арткан вакыт та.

(«Реальное время» электрон басмасы)

РОССИЯДӘ – ГАИЛӘ ТОРМЫШЫ

«РИА Новости» белгечләре кайсы төбәкләрдә гаиләләрнең ничек яшәгәнен ачыклаган. Уртача алганда, Татарстанда ике балалы гаиләдә минималь чыгымнардан соң аена 45552 сум акча кала икән. Узган елгы күрсәткечләр буенча республика – ил төбәкләре арасында 16 нчы урында.

	Төбәк	Ике балалы гаилә	Бер балалы гаилә
1	ЯНАО	118310	135249
2	Мәскәү	89626	102939
3	Сахалин	78624	95909
...			
16	**Татарстан**	**45552**	**59020**
...			
83	Чечня	2027	16342
84	Ингушетия	–203	15616
85	КБР	–7298	10432

Чаллы сайлады

Чаллыдагы 20 нче Электротехник округында Татарстан Дәүләт Советына өстәмә сайлауда иң күп тавышны Руслан Нигъмәтуллин җыйган. Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе хәбәренә караганда, башлангыч нәтиҗә буенча, бу кандидат өчен сайлаучыларның 74,44 проценты тавыш биргән. Икенче урында – Татьяна Мухина (6,87%). Адель Вахитов – 4,75%, Александр Быков – 4,47%, Илнар Сираев – 4,16%, Ирек Зыятдинов 2,45% сайлаучыдан хуплау тапкан. Сайлауда округта теркәлгән барлык сайлаучының 19,42 проценты катнашкан.

28 майда автомобиль төзүчеләр шәһәрендә VI чакырылыш Дәүләт Советы депутатын өстәмә сайлауда тавыш бирү өчен 24 сайлау участогы ачылган. Өстәмә сайлау үткәрү депутат Олег Коробченконың вәкаләтләреннән вакытыннан алда азат ителүенә бәйле: узган елның 15 июненнән ул Татарстан сәнәгать һәм сәүдә министры булып эшли.

Тиз күрәләр

Татарстанда «Алкоголь» операциясе барышында 3 мең литрдан артыграк күләмдә ялган хәмер һәм составында спирт булган продукция сатудан алынган. Барлыгы 75 закон бозу очрагы ачыкланган. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, ялган хәмер сату очракларына Мөслим, Балык Бистәсе, Югары Ослан, Яшел Үзән районнарында һәм Чаллыда тап булганнар. Моннан тыш хокук сакчылары хәмерле, спиртлы продукцияне законсыз җитештереп, сатуга чыгарган өчен 4 җинаять эше кузгаткан.

Ел башыннан Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре барлыгы 15 мең литр чамасы хәмер һәм спиртлы продукцияне, 78 мең литрдан артыграк метиллы сыекчаны тартып алган.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ҖИҢЕЛМӘС ӘРДОГАН

Майның соңгы атнасы бик киеренке узды. Америка техник дефолтка якынлашты. Әмма соңгы көннәрдә генә Байден үзенең оппонентлары белән әҗәт түшәмен янә күтәрү турында килеште. Дөрес, әлегә Конгресс карар кабул итмәде, әмма инде ышанып әйтергә мөмкин: хөкүмәткә киләчәктә яңа әҗәтләр җыярга рөхсәт ителәчәк.

Көтмәгәндә Әфганстан белән Иран чигендә хәл кискенләште. Ату тавышлары яңгырады, корбаннар да бар. Конфликт Әфганстаннан башланып, Иранның Систан провинциясендәге Хамун күленә коючы Гильменд елгасы суы аркасында килеп чыкты дип санала. Рәсми фараз шундый. Тәһран Кабулны, Гильмендны буып куеп, Иранга суны чикләүдә гаепли. Әмма Талибанның югары дәрәҗәдәге вәкиле Абдулхәмид Хөрәсәнинең Иранны Көнбатыш белән мәче-тычкан уены уйнауда, чынлыкта исә ислам дошманнары белән бер якта булуда гаепләгән белдерүе мәсьәләнең катлаулырак булуын күрсәтә. Хөрәсәни, илнең югары җитәкчелегенең рөхсәте булса, Тәһранны бер тәүлектә алачакларын да игълан итте. Әмма хәл әлегә ул дәрәҗәдә үк кискенләшмәде. Иран үзенең элиталы гаскәрләрен Әфганстан чигенә китерергә мәҗбүр булды.

Үткән атнаның дөньякүләм игътибар үзәгендәге төп вакыйгасы, әлбәттә, Төркиядә Президент сайлауның икенче туры иде. Хәлиткеч турны Америкада да, Европада да, Россиядә дә, Көнчыгыштагы гарәп илләрендә дә текәлеп күзәттеләр. Хәтта Америкада Трамп хакимлеккә килгәндә дә сайлау процессының ул дәрәҗәдә үк игътибарга алынуы булмады кебек. Тавыш бирү нәтиҗәләре дөнья сәясәтендәге төп фигураларның берсенә әверелгән илдә алдагы елларда үсеш векторын билгеләячәк иде.

Икенче турга әзерлек кискен көрәш шартларында үтте. Әрдоганның позициясе отышлырак иде. Беренче турда җиңү өчен аңа бик аз тавыш җитмәде. Сайлау алдыннан Әрдоган АКШ Президенты Байденның аны хакимияттән читләштерергә әмер бирүе хакында әйтте. Байден 2020 елда ук андый нияте барлыгын белдергән иде. Европа җитәкчелегендә дә төрек лидерын уен кырыннан чыгарып ташлау теләге көчле булды. Әмма сайлау участоклары ябылып, бик аз вакыт үтүгә, Әрдоганның алда баруы һәм җиңәчәге мәгълүм була башлады. Күп кенә ил лидерлары, Үзәк сайлау комиссиясе нәтиҗәләрне игълан иткәнче үк, аны җиңү белән котларга тотынды. Беренче булып Катар әмире үзенең «кадерле туган»ын бик җылы итеп котлады. Дохадагы Әл-Җәбер биналарына төрек флагы һәм Әрдоган портреты проекцияләнде. Барлык ил лидерлары (шул исәптән Байден да) котлау юлладылар. Котлаучылар арасында президентлар гына түгел, төрле сәяси оешмалар һәм төркемнәр җитәкчеләре дә күп иде. Хәтта Трамп – АКШның элекке президенты да мәдхия тулы котлау юлларга онытмады.

Якшәмбе кичендә төрек шәһәрләре урамнары тантана итте. Фетнә чыгу куркынычы да юк түгел иде. Әнкарада Кызылай мәйданына өстәмә полиция көчләре һәм хәтта хәрбиләр китерелде. Әмма урамнар бәйрәм төсендә иде. Газета хәбәрчесе кайсы да булса бер илдә сайлау нәтиҗәләре игълан ителер-ителмәс үк халыкның ул дәрәҗәдә сөенгәнен хәтерләми. Оппозиция үзенең җиңелүен таныды, хәтта каршы як лагерьдан да җиңүчене котлау авазлары ишетелде. Әрдоган рәттән унберенче сайлауда җиңде һәм төп сәяси көчләрнең берсе дә аның җиңүенә шик белдерә алмый.

Россиядә

ТЕХНОЛОГИК СУВЕРЕНИТЕТ ТӨЗЕГӘНДӘ

Россиянең икътисады һәм социаль тармагы дөнья сәясәтенең шахмат тактасында төп фигураларның нинди йөрешләр ясавына бәйле. Ул юнәлештә соңгы көннәрдә Кремль өчен берничә кыңгырау шалтырады.

Американың көндәлек газетасы The Wall Street Journal Согуд Гарәбстаны чиновникларының Мәскәүдәге коллегаларына нефть чыгаруны киметү турындагы вәгъдәләрен үтәмәүдә гаепләү юллауларын яза. Гарәпләр белән конфликт Мәскәүгә стратегик проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Июнь башында ОПЕК+ илләре яңа утырышка җыела. Утырышта Россия нефтьчеләренә басым ясалырга ихтимал. Мәскәүнең бурычы – яңа «кара алтын» җиһадына юл куймау. Якын Көнчыгышта Россия өчен башка проблемалар туу куркынычы да бар.

Тышкы проблемаларның ил эчендә бик тиз кайтаваз бирә торган чагы җитте. Ялгыш ясалган һәр адым матди югалтулар булып әйләнеп кайтачак. Тышкы базарлардан ничек кенә бәйсез булырга тырышсак та, котылгысыз рәвештә алар безнең икътисадка тәэсир ясый.

Беренче санкцияләр канонадасы яңгырагач ук, «Ватаным Татарстан»да әйттек: тышкы базарлардан башка гына үзебезнең технологик продукцияне җитештерү мөмкин түгел. Икътисадчылар шул фикерне раслый: планлы рәвештә зыянга эшли торган компанияләр төзергә туры киләчәк, диләр. Икътисадый үсеш министрлыгы җитәкчесе Решетников технологик суверенитет өчен 550 миллиард сум акча тотылуын, әмма инвестицияләрне кимендә 2,5 триллион сумга җиткерергә кирәклеген әйтә. Ул акча да әле иң мөһим тармакларда гына үз продуктларыбызны җитештерүгә ирештерәчәк. Путин да таныды бит инде: барлык импортны алыштыру мөмкин түгел. Максат кую һәм инвестицияләр ясау көтелгән нәтиҗәләргә китерер дип өметләнергә дә ярамый. 2001 елда ук элемтә һәм мәгълүматлаштыру тармагында үз җиһазларыбызның күләмен 20–30 проценттан 60–65кә җиткерергә дигән максат куелган. 2015 елга ул җиһазларның күләме 10 процентка гына калган. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми. Яңа технологияләр өчен бихисап акчаны суга салган Чубайс хәзер кайда? Израиль гражданлыгы алды һәм шунда яшәп ята. Шул сәбәпле хәзер дәүләтнең югары чиновниклары тыйнаграк максатлар куя, әмма аларының да үтәлеше шик астында, чөнки товарны «дус илләр»дән кайтару арзангарак төшә.

ТУГАННАРЧА КОТЛАУ

Татарстан Рәисе, «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме рәисе Рөстәм Миңнеханов Рәҗәп Тайип Әрдоганны Төркия Президентын сайлауда җиңүе уңаеннан котлады.



tatarstan.ru

«Төркия Республикасы Президентын сайлауда җиңүегез уңаеннан иң җылы котлауларны кабул итегез, – диелгән котлау телеграммасында. – Узган сайлау йомгаклары илдә яшәүчеләр арасында тел-теш тидергесез абруйга ия булуыгыз, Сезнең җитәкчелектә аларның актив төстә эшләргә һәм стратегик социаль-икътисадый бурычларны хәл кылуга әзер булулары турында сөйли. Ватандашларыгызның Төркия дәүләте язмышын һәм үз киләчәген Сезгә ышанып тапшыруы бүгенге дөньяда моңарчы күрелмәгән тотрыксызлык шартларында аеруча мөһим, һәм бу, көчле, тәҗрибәле дәүләт эшлеклесе, киләчәкне алдан уйлап эш итүче, талантлы сәясәтче буларак, какшамас абруегызны тагын бер кат раслый. Сезгә чын күңелдән биек үрләр, Төркия дәүләтен ныгыту һәм үстерү эшендә барлык стратегик максатларыгызга ирешүегезне, халкыгыз файдасына армый-талмый эшләвегезне телим!»

Рөстәм Миңнеханов Россия белән Төркия арасындагы мөнәсәбәтләр кысасында Татарстан – Төркия хезмәттәшлегенең уртак тырышлык белән алга таба да аларның нәтиҗәле төстә тормышка ашырыласына ышануын әйткән. «Тугандаш халыкларыбыз арасында төрле яклы элемтәләрнең тынычлык һәм үзара аңлашуны ныгытуга мөһим өлеш кертәчәгенә ышанам, – дигән ул. – Сезгә нык сәламәтлек, уңышлар һәм бәхет телим!»

Чисталык өчен бүләк

Татарстан Хөкүмәте йортында узган традицион киңәшмәдә санитар-экологик ике айлыкка йомгак ясадылар. Премьер-министр Алексей Песошин муниципаль берәмлекләргә һәм шәһәр округларына бүләкләр тапшырды.

«Шәһәр округлары» категориясендә беренче урынны Казан яулады, Чаллы – икенче урында. Район үзәге шәһәр булган муниципаль берәмлекләр арасында Кукмара – беренче, Әлмәт – икенче, Әгерҗе өченче урынны алды. Район үзәге шәһәр тибындагы бистә муниципаль берәмлекләр арасында Биектау – беренче, Саба – икенче, Чирмешән өченче урынны алды.

Татарстанда 1 апрельдә башланган санитар-экологик чараларда 688708 кеше катнашты. Бу эшкә 18 меңнән артык берәмлек техника җәлеп ителде. Полигоннарга 520 мең кубометр калдык чыгарылды. Яшелләндерү эшләре кысасында муниципалитетлар 650 мең агач һәм куак утыртты. Бу чорда күпсанлы табигать саклау акцияләре, массакүләм өмәләр, экологик дәресләр оештырылды.

БЕЛМИ КАЛМАСЫННАР!

Программалар күп, акча җитәрлек, аны алып, эшкә тотарга гына өлгер. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Югары Ослан районында авылда яшәүчеләрнең эшмәкәрлек активлыгын үстерү мәсьәләләре буенча зона семинар-киңәшмәсендә шулай диде.

Очрашуда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров, Җирле үзидарә органнары ассоциациясе советы рәисе Әгъзам Гобәйдуллин, Дәүләт Советы депутатлары, шулай ук 8 районның хакимият, авыл җирлеге башлыклары, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, гаилә фермалары җитәкчеләре, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре катнашты.

Республика парламенты башлыгы иң элек Югары Ослан районында җирле җитештерүчеләрнең сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукциясе күргәзмәсе белән танышты. Фәрит Мөхәммәтшин күргәзмә павильоннарында йөргәндә, фермерлар, эшкәртү предприятиеләре белгечләре, авыл эшмәкәрләре белән аралашып, министрлар һәм районнар хакимиятләре башлыклары игътибарын дәүләт ярдәмен күрсәтү аша авылда эшмәкәрлекне үстерүгә булышу зарурилыгына юнәлтте.

Дәүләт Советы Рәисе, семинар-киңәшмәне ачып, республика җитәкчелегенең һәм шәхсән Рәис Рөстәм Миңнехановның авыл халкына ярдәм итү, саланы үстерү мәсьәләләренә бик зур игътибар биреп килүен искәртте.

– Икътисадый кыенлыкларга, авылда яшәүчеләрнең картаюы һәм кимүенә карамастан, республикабыз күп кенә күрсәткечләр буенча Россиядә алдынгы урыннарны били, – дип искәртте Фәрит Мөхәммәтшин. – Узган елда 334 миллиард сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелде, рекордлы күләмдә ашлык җыеп алынды, сөт күләме беренче тапкыр 2 миллион тоннадан артып китте. Республика җитәкчелеге исеменнән хезмәтегез өчен рәхмәт белдерәм.

tatarstan.ru

Фәрит Мөхәммәтшин, район хакимиятләре башлыклары һәм авыл җирлекләре җитәкчеләрен, федераль һәм республика программаларында катнашу, авылны үстерү өчен, кешеләр белән ныграк эшләргә өндәде.

– Программалар күп, акча җитәрлек, аны алып, эшкә тотарга гына өлгер, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Актив, эшлекле якташларыгызга программаларда катнашырга, бирелгән акчадан файдаланырга һәм үз эшләрен башлап җибәрергә ярдәм итегез! Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга, гаилә фермалары һәм крестьян-фермер хуҗалыкларына бирелә торган акча, банк кредитларыннан аермалы буларак, кире кайтарылмый. Ул фермерның үзе өчен дә, авыл һәм тулаем район өчен дә «эшләячәк». Кызганычка, кайбер районнар моны аңлап бетерми. Безне әнә шул борчый.

Югары Ослан районы башлыгы Марат Зыятдинов үзләрендәге шартлар турында сөйләде. Районда 5 зур аграр хуҗалык, 37 крестьян-фермер хуҗалыгы һәм 3 меңнән артыграк шәхси ярдәмче хуҗалык эшләп килә. Узган елда авыл хуҗалыгына инвестиция күләме 3,5 миллиард сум тәшкил иткән.

Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров үзенең чыгышында авыл эшмәкәрлеге, кече һәм урта агробизнесны үстерү мәсьәләләренә кагылып үтте. Аның әйтүенчә, 2022 елда шәхси ярдәмче хуҗалыклар барлыгы 107,3 миллиард сумлык продукция җитештергән. Республика шәхси ярдәмче хуҗалыкларның җитештерү күләме буенча Россиядә икенче урында тора.

Киңәшмәдә районнардагы хуҗасыз объектларны яңадан рәсмиләштерү, сөт сату бәяләрен тотрыклыландыру чараларын эшләү, «Россельхозбанк»ның ташламалы 5 процентлы кредитын үзмәшгульләргә генә түгел, бәлки шәхси ярдәмче хуҗалыкларга да бирү зарурилыгына кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде.

КӘБЕСТӘ – АЛДАН, ШИКӘР АРТТАН ЙӨГЕРӘ

Бәяләр

Татарстанда бер ел эчендә шикәр комына бәяләр төшкән. Уртача алганда, татлы ризыкның бер килограммы 28 процентка арзанайган. Әйтик, узган елның маенда Татарстанда шикәр комының бер килограммы уртача 83,9 сум булса, быелның шушы чорына 60,2 сумны тәшкил итә. Тик сөенергә иртәрәк. Бер атна эчендә аның бәясе республикада 1,02 процентка күтәрелгән. Алда кайнатма, компот ясау сезоны башлануны искә алсак, бәяләр тагын да өскә сикерергә мөмкин. Татарстанстат тәкъдим иткән мәгълүматлар әнә шуны күрсәтә.

Исегезгә төшерәбез: узган елның язында әлеге продукт бик нык популяр булган иде. Кибет киштәсенә чыккан берен сатып алып бетерделәр. Мәсәлән, 2022 елның 3 мартыннан алып 9 мартына кадәр 1122 тонна шикәр сатылган иде. Шул сәбәпле аның бәясе дә өскә сикерде.

Хаклары төшкән ризыклар арасында карабодай да бар. Рәсми саннар аның бәясе ике тапкыр төшкәнлеген күрсәтә. Әгәр узган елның 10 маенда аның бер килограммы уртача алганда 120,3 сум булса, быел ул якынча 62,53 сум булган. Бер атна эчендә генә дә карабодай ярмасы 1,22 процентка арзанайган.

Ә менә хаклары арткан ризыклар исемлеге зуррак. Әйтик, ел башыннан яшелчә бәяләре аеруча зур тизлек белән өскә күтәрелгән. Биш продукттан торган кәрзин 1,7 тапкыр, ягъни 95,6 сумга арткан. 9 гыйнварда республикада яшелчәләр җыелмасының (һәркайсы берәр килограмм) уртача бәясе 134,84 сум булган. Әйтик, бер килограмм суган – 30,67 сум, чөгендер – 29,84, бәрәңге – 27,88, кишер – 27,36, ә кәбестә 19,09 сум булган.

Ә инде 22 майга яшелчәләр җыелмасы республикада 230,46 сумга җиткән. Барыннан да бигрәк суган һәм кәбестә хакы арткан. Суган 70,77 сумга менсә, кәбестә 48,22 сум булган. Соңгысының бәясе бер атна эчендә исә 52,26 процентка арткан.

КФУның идарә итү, икътисад һәм финанслар кафедрасы мөдире Игорь Кох фикеренчә, бер төр азык-төлекнең бәясе артып, икенчесенеке төшү – гадәти күренеш.

– Бу вакытта гадәттә яшелчәләргә бәя һәрвакыт арта, чөнки иске запас кимеп килә, ә яңа уңыш әле алынмаган. Ярма, яшелчәләргә караганда, ит бәясе акрынрак үсә. Чөнки базарда соңгы елларда аларга сорау кимү күзәтелә, – диде ул.

15 майдан 22 майга кадәр хаклары күтәрелгән ризыклар арасында югары сортлы бодай оныннан макарон һәм тавык ите дә бар. Моннан тыш, бер атна эчендә сарык ите (сөяксез иттән тыш), балалар ризыгы өчен коры сөт кушылмалары, тоз, каты, ярымкаты һәм йомшак сырлар, арыш һәм арыш-бодай ипиенә дә бәя арткан. Бик азга гына көнбагыш мае, маргарин, эремчек, печенье, бананның да уртача хаклары өскә менгән. Сүз уңаеннан, ел башыннан бананның бер килограммы уртача 36 процентка арткан.

Калган азык-төлеккә уртача бәя түбәндәгечә арткан: пешергән колбаса – 2,95 процентка (килограммы 396,25 сумга кадәр), тавык (тавык ботыннан тыш) – 2,84 процентка (163,98 сумга кадәр), югары сортлы бодай оныннан макарон – 1,41 процентка (67,12 сумга кадәр), бодай оны – 1,17 процентка (40,62 сумга кадәр).

Россия Хөкүмәтенең агросәнәгать комплексы департаментының элеккеге җитәкчесе, икътисад фәннәре докторы Леонид Холод сүзләренчә, россиялеләр, иттән баш тартып, күбрәк ярма һәм яшелчә ашый башлаган.

– Кайбер товарларга бәя күтәрелгәч, аларга сорау кими. Алар сыгылмалы дип атала, – дип аңлата белгеч. – Ә кайбер товарларга бәя артса да, ихтыяҗ кимеми. Тавык ите менә шундый товарлар исемлегенә керә иде. Ләкин быел хәтта аңа да сорау кимеде. Бу исә халыкның кереме шактый кимүне аңлата. Кешеләр камыр ризыклары һәм гади яшелчәләр ашауга күчә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТЫЛДА ТЫНЫЧ БУЛСА ГЫНА...

Батырлар

Ангелина ханым 2023 елны тулы гаиләсе белән каршы алырга өметләнә. Әмма Яңа елга санаулы көннәр калганда, ирен махсус хәрби операция зонасына озатырга туры килә... Рухы сынарга торганда, нәкъ үзе кебек хатын-кызларга, әниләргә, сеңелләргә ярдәм итү бик булыша аңа.

– Тормыш иптәшем һөнәре буенча – хәрби. Холкы һөнәренә бик туры килә аның. Көчле рухлы кеше, – ди Ангелина Галимова. – Аны күтәп алырга «Ватан алдындагы бурыч» гыйбарәсенең мәгънәсен аңлау да булыша. Бу гыйбарәгә төрле кеше төрлечә карый. Әмма мин аның мәгънәсенә инде күптән төшендем. Ирем миңа гел: «Бар шундый һөнәр: Ватанны саклау», – дип әйтә иде. Бу хакта хәрбиләргә дә, якыннарына да онытмаска кирәк.

Ангелина Галимова Ватан сугышчылары гаиләләре комитетының Татарстандагы бүлеген җитәкли. Әлеге комитетның төп бурычлары – махсус хәрби операция зонасындагы ир-егетләрнең әти-әниләрен, бертуганнарын, хатыннарын һәм, гомумән, якыннарын берләштерү, аларга ярдәм күрсәтү.

– Кайчак, психологлардан бигрәк, синең кебек үк хәлдә калган кеше белән сөйләшеп утыру күбрәк булыша. Күпләр өчен аларны тыңлау да җитә. Дөресен генә әйткәндә, безнең күңелләребез аша нечкә генә җепләр сузылган кебек. Шуңа без бер-беребезгә чын мәгънәсендә ярдәм итә алабыз. Әйе, хәлләребез охшаш булса да, вазгыять төрле булырга мөмкин. Кемдер авыррак, кемдер җиңелрәк кичерә аны. Андый чакта башкаларны тыңлауның файдасы күп, – ди Ангелина Галимова.

Комитетка теләгән һәркем ярдәм сорап мөрәҗәгать итә ала. Күбесенчә хәрби бурычын үтәүче якыннары өчен борчылып киләләр икән. Аңлатырга да, юатырга да туры килә аңа. Сүзләрен каян табып бетерәдер?

– Яшермим, нәрсә әйтергә белмичә аптыраган чаклар да була. Ләкин күзгә-күз очрашкач, үзеннән-үзе сөйләшеп кителә. Үзем дә хәрби хатыны булгач, күрәсең, сүзләр табыла, – ди әңгәмәдәшебез.

Үзенә дә авыр инде, яшерми. Башкаларга ярдәм итә алуы белән юана, шуннан көч ала Ангелина ханым. Хәрби бурычын үтәүче ире белән аралашу да канатлар куя икән.

Ә зарлы күз яшьләре, курку, төшенкелеккә бирелү бернәрсәне дә үзгәртә алмый. Ир-егетләр тылда тәртип һәм тынычлык булуына инанырга тиеш, ди әңгәмәдәшебез. Бик тә авыр чакта көчле таянычыбыз – дин барлыгын онытмаска чакыра ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

vk.com

Ирләре хәрби хезмәттә булган хатыннарга Ангелина ГАЛИМОВА киңәшләре:

– «Мотивация» дигән нәрсә бар. Ул булмаган очракта, гомереңне саклап калу кыенрак. Егетләребез зарлана икән, «Әйдә, аннан кайтарып булмасмы, бер-бер нәрсә эшләп карыйк» ише сүзләр әйтмәвең хәерле. Бу хакта психологлар искәртә. Мондый уй аңына керә икән, бетте, ул инде 100 процентка анда булмый. Алда әйткән мотивациянең эзе дә калмый. Шөкер, безнең егетләр кем белән һәм нәрсә хакына көрәшкәнен яхшы аңлый. Без дә истә тотсак иде шуны. Якты, матур, ә иң мөһиме – уртак киләчәккә өметләндерергә кирәк. «Син кайтырга тиеш!» кебек сүзләрне ешрак кабатлагыз. Һәм, әлбәттә, горурлануыгыз турында һәрчак искәртеп торыгыз.

Спорт

БЕРЕНЧЕДӘ – БЕРЕНЧЕ

«Рубин» – чемпион! Казан футболчылары тамашачыга биргән вәгъдәсен үтәде һәм беренче лигада җиңүче булып танылды. Чемпионат тәмамланырга бер атна кала «Ак барс Арена»да бәйрәм оештырдылар.

Рәхмәт «Балтика»га! Сезон буе беренче урында барган Калининград командасы, башта үз кырында «Рубин»га җиңелеп, лидерлыкны кулдан ычкындырды, аннары «Алания»гә дә оттырып, безнекеләргә бәйрәм оештыру мөмкинлеге бирде. Казанда исә мөмкинлекне кулдан ычкындырмадылар. «Ак барс Арена»да узган очрашуда «Рубин» Махачкала «Динамо»сын 2:0 исәбе белән җинде. Сүз уңаеннан, ике тупны да Джоэль Фамейе кертте һәм 11 гол белән команданың иң нәтиҗәле һөҗүмчесе булып танылды. Икенче тубын керткәч, һөҗүмче кызган баштан ак түбәтәй киеп куйды. Әмма бик тиз салдырдылар. Чөнки былтыр «Уфа»га каршы узган уенда Виталий Лисакович туп керткәч, футболчыларның матч барганда өелешеп фотога төшүе, ә аннары команданың оттырып, премьер-лигадан төшеп калуы әле дә истә. Кыскасы, уйнагач, ягъни эш беткәч кенә шаярырга ярый.

Соңгы тапкыр «Рубин» зур җиңүгә 2012 елда ирешкән иде. Ул елны Казан командасы Россия Кубогына ия булды. Финал очрашуы Екатеринбургта узды. «Ак барс Арена»да исә мондый бәйрәм тәүге мәртәбә оештырыла. Клуб президенты Марат Сафиуллин рәхмәт сүзләрен кызганмады.

– Бу сезон безнең өчен катлаулы һәм кызык булды. Үзенчәлекле командалар һәм матур уеннар күрдек. Татарстан җитәкчелегенә, беренче чиратта, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка рәхмәт, – диде ул. – Баш тренерга, аның штабына, бөтен коллективка һәм, әлбәттә, җанатарларга рәхмәт. Сезнең ярдәм белән катлаулы чорны уза алдык. Алга, «Рубин»!

Марат Сафиуллинның җанатарларны аерым телгә алуы юктан түгел. Сезон уртасында команданың тамашачы белән арасы бозылган вакытлар да булды. Команданың премьер-лигага әйләнеп кайта аласына шикләнүчеләр дә артты. Шикне бетереп, өметне арттыру өчен, Казан клубында үзгәртеп кору адымына барырга туры килде.

Кубокны исә ике капитан – Александр Мартынович белән Олег Иванов бергәләп күтәрделәр. «Хәзер инде узган уен турында сөйләшүнең мәгънәсе юк. Шушы ике айда ни эшләвегез турында гына әйтәсе килә. Тырыштыгыз, бердәм булдыгыз, җиңү һәм көндәшне куып тоту теләген күрсәтә алдыгыз. Һәрберегез алга таба бер адым атлады. Эшкә мөнәсәбәтегез гаҗәеп дәрәҗәдә шәп булды», – диде баш тренер Рәшит Рәхимов.

Бу составның беренче лигада тагын бер очрашу уздырасы калды. Премьер-лигада чыгыш ясар өчен үзгәрешләр кирәк булачак. Әмма үзгәртеп кору түгел. Анысы белән соңгы вакытта «Рубин»да артыгын мавыктылар.

	Команда	уен	очко
1	Рубин	33	68
2	Балтика	33	64
3	Алания	33	59
4	Енисей	33	53
5	Родина	33	49
6	Шинник	33	46
7	Динамо Мх	33	46
8	КАМАЗ	33	44
9	Волгарь	33	44
10	Нефтехимик	33	44
11	Акрон	33	43
12	Арсенал	33	41
13	СКА-Хабаровск	33	41
14	Кубань	33	34
15	Велес	33	33
16	Уфа	33	32
17	Волга Ул	33	29
18	Краснодар-2	33	28

rubin-kazan.ru

99 суган

Яшәеш

Май яллары алдыннан Балтачтагы базарга орлыклар-үсентеләр алырга бардым. Кукмарадан килеп, ел да үсентеләр, орлыклык суган сатучы абыйда миннән алда берничә кеше бар. Шул чакта күптәнге танышым килде дә: «Абый, миңа 99 суган калдырырга онытма, сатып бетермә», – дип китте.

Түзмәдем: «Гомергә уен-көлкеле булдың инде, суганны да безнең кебек килолап түгел, штуклап аласың», – дим, шаяртуына тамчы да шикләнмичә. Шаяртмый икән.

– Миңа түгел, балаларга бу суган. Бәйрәмгә кайткач, алып китәрбез, дигәннәр иде, – ди бу. – Үз йортлары белән яшиләр, участокларында аз гына буш урын калган. Суган утыртканнар иде инде, теге урын да буш калмасын дигәннәр. «Санап, исәпләп караган идек, 100 штук суган кирәк. 99ны гына ал, берсен диван астыннан таптык», – дип шалтыраттылар. Артыгы нәрсәгә аның, диләр.

Менә, ичмасам, төгәл, конкрет кешеләр, дип аптырадым мин. Кемнәргәдер бу ваклык булып тоелырга мөмкин. Әмма, күпләребез кебек, кирәксә-кирәкмәсә, килолап алып, калганын әрәм-шәрәм иткәнгә караганда, исраф итми яши белүчеләргә афәриннән башка сүз юктыр. Язын, кызыга-кызыга, орлык җыябыз да, икенче елны утырта башлагач, элекке елгы әллә никадәр орлык килеп чыга. Күпләр шулай ди. Аннан иске орлыкларны ничек «уятырга» икән дип, интернеттан киңәшләр эзли башлыйбыз. Әле бит анысын «уятсаң», быелгысы киләсе елга калырга мөмкин.

Шул ук базарның икенче почмагында атнага ике көн Балык Бистәсенең танылган эшмәкәре Ленар күз явын алырлык чәчәкләр, агач-куаклар белән сату итә. Анда ничә барсаң да, чират бетми, иң «кайнап» торган урын бу. Ленар сөйли: «Синең янга килергә дә куркабыз, ди танышлар. Күреп кызыгабыз да тагын чәчәк-гөл җыя башлыйбыз, диләр».

Минем күз алдымда гына ике ханымның берсе – алтмыш, икенчесе йөзләп петуния алды. Әле тагын башка төрле чәчәкләр дә алдылар. «Үзебезнең бакчага ел да шулай күп итеп утыртабыз. Язын менә шулай меңәр сум түләп, чәчәк алабыз да көзен җыештырып түгәбез, – ди аларның берсе. – Әмма чәчәк утыртмыйча да булмый. Җәй буе сокланып, хисләнеп йөрисең бит...» Әнә шулай, матурлык булдырабыз дип, үз хуҗалыкларына утырту өчен ел да илле мең сумга кадәр чәчәк алучыларны беләм. «Быел әле Балтач базарына менеп җитмәдек, үзебезнең авылга китереп сатучылардан, Смәелдән генә күпләп алдык», – ди гөлләр-чәчәкләр яратучы, зур ихатасын ел да чәчәкләр патшалыгына әйләндерүче танышым Илфак. Бакчачылык, гөлләр үстерү хатын-кыз эше кебек тоелса да, арабызда матурлык яратучы ир-егетләрнең булуы бик әйбәт. Күбесе аны кәсеп итеп, тормыш та алып бара бит әле...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ЧАБУДАН ТАРТА

Россиядә кредит буенча бурычларын вакытында түләп бара алмаучылар саны арткан. «Федресурс» бердәм федераль реестры белгечләре шулай дип ышандыра. Бурычы чабудан тартучыларның күбесе банкротлыкка чыга, ди алар. Быелның беренче кварталында гына да Россиядә 76 мең кеше үзен банкрот дип игълан иткән. Бу, узган елның шул чоры белән чагыштырганда, 40 процентка күбрәк. Банкротлыкка чыгу нидән гыйбарәт соң?

vk.com

Яшерен-батырын түгел, күпләр бу процедурага шикләнебрәк карый. Аны киләчәктә акчага бәйле күп кенә мөмкинлек-эшләргә киртә куючы кәләймә итеп кабул итәләр. Белгечләр исә башка фикердә. Юрист Роман Архипов кредит буенча бурычларын түләп барырга көче җитмәгән һәм моны алга таба да башкара алмаячагын төгәл белгән кешегә үзен банкрот дип игълан итүдән дә яхшысы юк дип саный.

– Яшерен-батырын түгел, кредит буенча бурычын түләмәүчеләргә иртәме-соңмы коллекторлар белән эш итәргә туры килә. Хәлне моңа кадәр үк җиткермим дисәң, үзеңне банкрот дип игълан итүдән дә яхшысы юк. Тискәре яклары шактый булса да, матди авырлыклар аркасында кредитын түли алмаган кеше өчен бик яхшы коткару чарасы булып тора ул, – дип саный юрист.

Роман Архипов сүзләренә караганда, хәзерге вакытта үз-үзеңне банкрот дип игълан итүнең ике юлы бар. Аның беренчесе – судсыз гына, икенчесе суд аша башкарыла. Бу ипотека кредитына да, куллануучыныкына да бер үк дәрәҗәдә кагыла.

Судсыз юл акчалата бурыч күләме кимендә 50 мең сум һәм күп дигәндә 500 мең сум тәшкил иткән кешеләргә туры килә. Бу – бик тиз, җиңел һәм, иң мөһиме, бушлай эшләнә торган ысул. Әмма үзеңне әлеге ысул ярдәмендә банкрот дип игълан итүнең берничә шарты бар. Моның өчен кешенең айлык түләүләр буенча бурычлары җыелган булу гына җитми. Кредит бирүченең, бу кешене судка биреп, суд приставларының аның бөтен милкен, исәп-хисап счетларын тикшереп тә берни тапмаган булуы кирәк. Шушы процедураларны үткәннән соң гына кеше, үзен судсыз гына банкрот итеп тануларын сорап, күпфункцияле үзәк аша гариза яза ала.

– Кредит буенча бурыч күләме 500 мең сумнан артып, аны ким дигәндә өч ай дәвамында түләмәгән кеше исә үзен суд аша гына банкрот дип игълан итә ала. Бу очракта эшне Арбитраж суды тарафыннан билгеләнгән финанс идарәчесе алып барачак. Суд аша үзен банкрот дип тануларын теләгән кеше иң элек шушы финанс идарәчесенә кайсы кредит бирүчегә күпме күләмдә бурычы барлыгы турында тулы мәгълүмат бирергә тиеш, – ди юрист. – Финанс идарәчесе, кредиты буенча бурычлары җыелган кешенең судка мөрәҗәгать итәргә җыенуын хәбәр итеп, шушы кредит бирүче оешмаларга белдерү юллаячак. Алга таба ул, кешенең милке турында мәгълүмат туплап, аның, дөрестән дә, башка чарасы юклыгына инангач, Арбитраж судына мөрәҗәгать итү өчен гариза әзерләп бирәчәк. Судсыз гына башкарыла торган юлдан аермалы буларак, суд аша үзеңне банкрот дип игълан итү – түләүле хезмәт. Моның өчен финанс идарәчесенә уртача 100–150 мең сум акчаңны чыгарып салырга туры киләчәк.

Бу процесс алты айдан өч елга кадәр сузылырга мөмкин. Бар да кешенең ничә оешмага күпме күләмдә бурычлы булуына бәйле.

– Судка гариза тапшырганнан соң, беренче утырыш уза. Анда гаризаның нигезлеме-түгелме икәнлеге тикшерелә. Гариза нигезле дип танылса, шул көннән башлап, бурычлы зат үзенең милке, исәп-хисап счетларындагы акча белән идарә итә, яңа исәп-хисап счетлары ача, аларга кертемнәр кертә алмый. Болар белән аның исеменнән финанс идарәчесе шөгыльләнә. Алар кешенең бурычларын түләүгә тотылачак. Бары шуннан соң гына кеше банкрот дип игълан ителәчәк, – ди Роман Архипов.

Сүз уңаеннан, Арбитраж суды банкротлыкка чыгу турында гаризаны тикшерү барышында кешенең кайбер кырын эшләре дә фаш ителергә мөмкин. Яшерен-батырын түгел, банктан кредит алганда күпләр айлык керемен арттырып күрсәтергә тырыша. Моның өчен ялган 2-НДФЛ документы ясатучылар да шактый. Әмма кешене банкрот дип тану турында гаризаны тикшергәндә болар барысы да күренәчәк. Суд, әлбәттә инде, андый кешене банкрот дип танудан баш тартачак. Шул рәвешле бурычтан арынырга теләсәң, намусыңның да чиста булуы сорала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сорау – җавап

– Үзеңне ничә тапкыр банкрот дип игълан итәргә мөмкин?

– Биш елга бер тапкыр банкрот дип игълан итәргә рөхсәт ителә.

– Банкротлыкка чыккан кеше яңадан кредит ала аламы?

– Ала, әмма авырлыклар да килеп чыгарга мөмкин. Ник дигәндә, банкротлыкка чыгу кешенең кредит тарихына тискәре йогынты ясый. Моннан тыш, банкрот дип игълан ителгәннән соң, кеше алдагы биш ел дәвамында идарә белән бәйле вазыйфаларны башкара алмаячак. Үз эшен ачып, шәхси эшмәкәр буларак теркәлүдән дә мәхрүм булачак.

– Ипотекага фатир алган кеше үзен банкрот дип игълан итсә, ул бу торактан колак кагачакмы?

– Әйе. Ипотекага фатир алган кеше үзен банкрот дип игълан итәргә җыенса, аңа шушы торакны алырга акча биргән банк фатирны үзенә алачак, ягъни ул фатир банкротның милке булудан туктый.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «СКС ТӨЗҮЧЕ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзелеш-монтажлау эшләре участогы башлыгы **Дәүләтов** Зөфәр Мирхәйдәр улы; күпьеллык нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Сафин** Факил Миңнемөхәммәт улы; күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге һәм республика халкына транспорт хезмәте күрсәтүгә зур өлеш кертүе өчен «Буревестник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Улитин** Вячеслав Михайлович; Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен хезмәт ветераны **Фәрдиев** Феликс Шәех улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен «Лениногорскиның 6 номерлы территориаль җирле үзидарә иҗтимагый советы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы рәисе урынбасары **Копылова** Наталья Владимировна **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республикада музей эшен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле иҗади хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – А.М. Горький һәм Ф.И. Шаляпин музее өлкән фәнни хезмәткәре **Белова** Людмила Борисовна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Мөслим үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасы табибы – акушер-гинекологы **Әхкәмова** Рәйханә Рәшит кызына, «Әлмәт стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибы **Госманов** Шәүкәт Галимҗан улына, «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең медицина ярдәменең сыйфатын экспертизалау бүлеге мөдире – 1 нче поликлиника табиб-терапевты **Касыймова** Роза Габделхак кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 1 номерлы функциональ диагностика бүлекчәсе функциональ диагностика табибы **Мөхәммәтшина** Фәридә Наил кызына, «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Сидуков** Азат Алексеевичка, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Медицина-санитария часте гинекология бүлекчәсе мөдире – табибы – акушер-гинекологы **Фәйзрахманова** Лилия Расих кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе 3 номерлы поликлиникасының 2 номерлы педиатрия бүлекчәсе участок табиб-педиатры **Шишкова** Анна Григорьевнага, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең анестезиология-реанимация бүлекчәсе табибы – анестезиолог-реаниматологы **Юнысова** Гөлсинә Муллахмәт кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы һәм Лаеш шәһәренең «Район мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең 21 номерлы филиалы – Сокуры авылы мәдәният йорты мөдире **Шатрова** Ольга Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ТЕХНИК ЗАКАЗЧЫ-РЕГИОН» акционер җәмгыятенең Казан шәһәрендәге аерымланган структур бүлекчәсе (АСБ) директоры **Харитонов** Рамил Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Никольское урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Толокнова** Вероника Геннадьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

ӘЙЛӘН-БӘЙЛӘН

ЛАЕШ РАЙОНЫНЫҢ НИКОЛЬСКОЕ АВЫЛЫНДА 31 НЧЕ ТАПКЫР КАРАВОН БӘЙРӘМЕ ГӨРЛӘДЕ

Бу авылда, мөгаен, иң өлкән яшьтәге әби-бабайлар да: «Менә без үскән чакта бар иде хәлләр...» – дип, элеккеге вакытларны исләренә төшереп маташмас. Булдыра да алмаслар. Нигә дисәгез, еллар түгел, гасырлар тузаны каплаган гореф-гадәтләр бөтен тирә-якны гөрләткән Каравон фестивале ярдәмендә инде күптән барыбызның да күз алдына. Өстәвенә ел саен яңалыклары да, осталыклары да арта тора.

tatarstan.ru

Бәйрәмдә катнашучыларны һәм кунакларны Татарстан Рәисе, шулай ук республика Хөкүмәте исеменнән сәламләргә һәм котларга килгән Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыкları ассамблеясы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да нәкъ шундый фикерен җиткерде.

– Бу бәйрәм ярдәмендә рус этносының үзенчәлекле мәдәнияте югалып калмый, киресенчә, елдан-ел аны белүчеләр, ихтирам итүчеләр арта гына бара. 173 милләт вәкиле дус һәм тату яшәгән Татарстанда рус мәдәнияten һәм гореф-гадәтләрен саклауга зур әһәмият бирелә. Шунысы мөһим: мондый бәйрәмнәр берләштерә, менә бүген дә рус Каравоны татарларны, чуашларны, удмуртларны, марийларны һәм башка халыкларны җыйды, республика өчен билгеле вакыйгага әверелде. Фестивальнең географиясе дә киңәя. Илебезнең төрле төбәкләреннән, хәтта чит илләрдән дә коллективлар килә, – диде парламент җитәкчесе. Фестиваль башланыр алдыннан парламент рәисе Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов белән бергә осталар ярминкәсен карады. Анда талдан үрелгән, балчыктан, каен тузыннан, киннән, тимердән һәм тукымадан ясалган эшләнмәләр тәкъдим ителде.

Быелгы кунаклар өчен иң зур сюрприз, мөгаен, борынгы аттракционнардан торган балалар һәм яшьләр паркы булгандыр. Аларны XVIII–XIX гасырларда уен ясалган үрнәкләр буенча агачтан иҗат иткәннәр. Уҗләре гади, уҗләре кызык, әйтерсең лә ниндидер сер саклыйлар.

Бернича мәйданда барган концертларның иң саллысы, әлбәттә инде, «Халык артисты» проектында финалга чыккан җырчы Марина Девятова катнашканы булды. Кунаклар шулай ук Мәскәү дәүләт мәдәният институты белән Россия музыка академиясе хорын да бик яратып тыңлады. CKAZKI төркеме дә, рус халык җырларын заманча итеп, поп-музыка стилендә «төреп» бирде. Татарстан сәнгать осталары яңашәсендә илебезнең төрле төбәкләреннән килгән 170тән артык коллектив чыгыш ясады. Алар арасында Удмуртия, Мари Эл республикаларыннан, Ульяновск, Самара өлкәләреннән, шулай ук Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләреннән килүчеләр бар иде. Әлбәттә инде, төп игътибарны алып торучы мәйдан ул – әйлән-бәйлән аланы. Бу аланда бәйрәм итүчеләр, бөтен шартына туры китереп, чәнти бармакларны гына тотышып, «урдәк адымы» белән гел әйлән-бәйлән әйләнделәр.

Аңлашыла ки, фестивальнең максаты – Татарстанда рус фольклорына игътибарны арттыру, борынгылардан гореф-гадәтләрен саклау һәм җәелдерү булса да, беренче чиратта бу бәйлыкның барысын да яшь буынга җиткерү. Шуңа күрә дә балалар өчен оештырылган мәйданчыклар милли уеннар һәм мастер-класслардан шаулап торды. Монда гадәттәгечә алагаем зур батутларны күрәм, димә. Барысы да XVIII гасырларда бик популяр булган уеннар рәвешендә эшләнгән. Атта йөрүне дә һәркем яратып калыр итте. Бәләкәйрәкләре дә аптырап тормады, әти-әниләре белән атлы арба янынарак елышты.

Әлбәттә инде, бүген бер генә бәйрәмне дә сәүдәдән башка күз алдына китерең булмый. Авыл урамнары бүйлап урнашкан ярминка рәтләре бик бай. Балалар уенчыклар янында мәш килсәләр, өлкәнрәкләр күбрәк кием-салым янында бөтерелә. Төрле-төрле сувенирлардан күзләр камаша. Шунда ук төрле һөнәрләр, иконалар язу, кыңгырау чыгалтып карау, тимерчелек эшләре буенча остаханәләр оештырылган. Рус киемнәре күргәзмәсенә килеп чыгучылар борынгы заманда халыкның ничек киенгәнен бик кызыксынып өйрәнделәр. Тамак ачып китсә, мичтә пешкән тәм-томнардан исе ерактан ук үзенә ымсындырып торды.

Әйтергә кирәк, быелгы бәйрәмнең күзгә чалынып торган уңай яклары күп булды. Бу хакта Лаеш районы башлыгы үзе дә искә алып китте. «Узган ел әйтелгән тәнкыйть сүзләрен истә тотып, мәдәният йортын яңарттык, машина кую өчен җитәрлек урыннар әзерләдек», – диде ул. Әмма камиллеккә чикләр юк дигәндәй, киләсе бәйрәмдә арып-талып тамаша кылып йөргән халык өчен ял итү нокталары, сәхнәләр каршында концерт тыңлаучы өчен утыргычлар күбрәк булса, комачауламас иде кебек.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

tatarstan.ru

БЕРЕНЧЕ БӘЙРӘМ

ДӨЯЛӘР ЧАБЫШЫ, МИЛЛИ КӨРӘШ ҺӘМ ЭТНОАВЫЛ: XIII БӨТЕНРОССИЯ АВЫЛ САБАН ТУЕ НӘРСӘЛӘР БЕЛӘН ИСТӘ КАЛДЫ?

Башкаларга охшамаганлыгын һәр елны дәлилләп тора ул. Бөтенроссия авыл Сабан туе быел Әстерхан өлкәсенең Три Потока – Җәмәле авылында гөрләп узды. Әстерхан илнең 30 төбәгеннән 50 меңнән артык кунакны җыйды. Чабышлы, көрәшле, этноавыллы, җырлы-биюле милли бәйрәмдә «ВТ» хәбәрчесе дә булып кайтты.

Иске Кангада – кечке Сабан туе

Бөтенроссия авыл Сабан туе татарлар яши торган көньяк өлкәләрнең берсе булган Әстерхан ягында беренче тапкыр үткәрелде. Ике көнгә сузылган бәйрәм чаралары өлкәнең татарлар күпләп яшәгән авылларында барды. Сабан туе Нариман районының Иске Канга авылында кичке якта концерт белән башланып китте. Татарстан җырчылары һәм ансамбльләре Әстерхан халкына дәртле җырлары белән күтәренке кәеф бүләк итте. «Мондый зур тамашаны күргәнебез булмады», – дип сокланып калды авыл халкы.

Бәйрәмнең Иске Канга авылында башлануы очраклы түгел. 4 авылны берләштергән узәктә 11 меңнән артык кеше яши. Аларның 5 меңнән артыгы – татар. Бирегә татарлар 1782 елда Казан губернасыннан күченеп килгән.

– Безнең авылда Сабан туе 2011 елдан бирле узмады. Җәмәлегә яки башка күрше-тирә авылларга бәйрәм итәргә бара идек. Бусын бик зарыгып көттек. Соңгы елларда бәйрәмнәр актив оештырыла башлады. Балалар гореф-гадәтләрне күреп үсә, җырларны ишетә, – диде авыл җирлеге башлыгы Рамил Каһарманов.

Бәйрәм кунакларын Әстерхан өлкәсенең вице-губернаторы Павел Паутов һәм Татарстан Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразыев сәламләде.

Васил Шәйхразыев татар милләтен, мәдәниятен үстерүгә зур өлеш керткән әстерханлыларны бүләкләде. Күркәм гадәте буенча сәхнәдән халыкны да җырлатты ул. Әстерхан татарлары «Кубәләгем»не көйләделәр.

Сизелеп тора: Әстерхан өлкәсе җитәкчеләре дә, анда яшәүче халык та Татарстанга хөрмәт белән карый. Халык белән аралашканда, балалары Казанда белем алган, туганнары Татарстанда яшәгән кешеләрне күп очраттык.

– Авылыбыз бик матур, зур мәчетебез бар. Халкыбыз тырыш, кулларыннан бар эш килә. Авылда Сабан туеның күптән узганы юк иде. Ә бит аның мәдәниятне, телне, традицияләрне саклауда роле зур. Татарстанда туганнарыбыз яши. Еш очрашып булмаса да, гел аралашып торабыз. Безнең өчен бик матур бәйрәм оештырганнар, аның тәэсире белән әле озак йөрермен дип уйлыйм, – дип сөйләде Иске Канга авылыннан Рузия Вәлиева.

Дуслык авылы

Милли рухта бәйрәм икенче көнне җәелеп китте. Әстерхан шәһәреннән 12 чакрым ераклыкта урнашкан Җәмәле авылы Бөтенроссия авыл Сабан туеның төп урыны булды. Бирегә илнең 30дан артык төбәгеннән халык җыелды. Җәмәле авылында Сабан туеның төп чаралары – милли уеннар, җыр һәм биюләр, ат чабышы, көрәш, капчык киеп йөгерү, аркан тарту һәм башка бәйгеләр узды.

Сабан туе мәйданчыгына керү белән кунакларны Этноавыл дип аталган 11 төрле халыклар ишегаллары каршылады. Һәр милләтнең үзенчәлекле мәдәнияте белән махсус корылган чатырларда танышырга мөмкин булды.

Милли утарлар буенча йөрибез. Җырлыйлар, биилӛр, уен коралларында уйныйлар, милли ризыклары белән сыйлыйлар. Әнә төрекмән кызлары һәм апалары милли киемнәрдән халык биюен биеп тора. Башкорт утарында кымыз, бал белән сыйланырга кыстыйлар. Камыр ризыкларын да мулдан пешереп килгәннәр. Милли киемнәрен, уен коралларын да онытмаганнар. Татарстанны исә быел да Кукмара районы тәкъдим итте. Кукмара итегенә, савыт-сабасына сорау җитәрлек иде. Табаларын, киемнәрен хәзер Әстерхан халкы да кулланачак, димәк.

Сабан туеның ачылу тантанасы һәм концерт төп сәхнәдә узды. Татарстаннан һәм Әстерханнан 900дән артык иҗади коллектив һәм артистлар чыгыш ясады. Бәйрәм театральләштерелгән тамаша форматында узды.

БӨТЕНРОССИЯ АВЫЛ САБАН ТУЕ БАТЫРЛАРЫ

Яшьләр арасында:
60 кг үлчәү авырлыгы – **Сабир Асейнов (Чувашия);**
80 кг үлчәү авырлыгы – **Булат Яруллин (Татарстан);**
110 кг үлчәү авырлыгы – **Рәҗаб Магомедов (Әстерхан өлкәсе).**

Ир-атлар арасында:
65 кг үлчәү авырлыгы – **Леонид Савхаев (Калмыкия);**
75 кг үлчәү авырлыгы – **Айназ Тимиров (Татарстан);**
85 кг үлчәү авырлыгы – **Азат Габдрәшитов (Татарстан);**
100 кг үлчәү авырлыгы – **Элдар Хәмитов (Татарстан).**

Абсолют үлчәү авырлыгында **Раил Нургалиев** җиңү яулады.

Сан

✓ XIII Бөтенроссия авыл Сабан туен **50** меңнән артык кеше тамаша кылды.

✓ Әстерхан өлкәсе Җәмәле авылында узган бәйрәмгә Россиянең **30** төбәгеннән кунаклар килгән иде.

✓ Иҗади программада катнашучылар саны **900**дән артык. Бу – Татарстан һәм Әстерхан өлкәсенең иң яхшы артистлары, сәнгать коллективлары.

✓ **70**тән артык декоратив-гамәли сәнгать остасы үз эшләнмәләрен тәкъдим итте.

Россиядә беренче!

Сабан туе мәйданчыкларын йөреп чыкканнан соң, бәйрәмне рәсми төстә Әстерхан өлкәсе губернаторы Игорь Бабушкин һәм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ачып җибәрде.

– Сезне чын күңелдән үзебезнең иң яраткан Сабан туе бәйрәмебез белән котлыйм. Бүген мөһим вакыйга. Сабан туйларын башлап җибәрәбез. Бу Россиядәге беренче Сабан туе, үзебездә Татарстанда да булмады әле. Әстерхан өлкәсе губернаторы Игорь Юрий улына, аның командасына зур рәхмәт әйтәсем килә. Бәйрәм бик матур оештырылган. Килгән делегацияләргә, Әстерхан халкына да зур рәхмәт. Сабан туе ул – сабан бәйрәме! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Игорь Бабушкин Әстерханда Сабан туеның һәрвакыт зурлап үткәрелүен әйтте.

– Әстерханда Бөтенроссия авыл Сабан туен уздыру – безнең өчен зур горурлык. Ул – безнең күпмилләтле өлкәбезне берләштерүче бәйрәмнәрнең берсе. Кадерле кунакларыбызны каршы алуыбызга шатбыз. Һәрберегезгә тынычлык, иминлек һәм уңышлар телим, – диде өлкә башлыгы.

Киләсе Бөтенроссия авыл Сабан туе исә Пермь өлкәсе Барда районында узачак. Әстерхан башлыгы бәйрәмнең символы – «Тулпар ат»ны Пермь крае губернаторы Дмитрий Махонинга тапшырды.

Чабыштылар... дөяләр

Авыл Сабан туенда Россиядә бердәнбер (!) дөя чабышы да уздырылды. Бу өлкәдә инде 20 ел дәвамында дөяләрне ярыштыралар икән. 2000 метр дистанциягә чабышта Әстерхан өлкәсе районнарыннан һәм Калмыкия Республикасыннан 18 җайдак катнашты. Ике чабыш нәтиҗәләре буенча финалга 10 кеше чыкты. Чемпион исемен Калмыкия Республикасыннан Дамир Дюсенбаев яулады. Дамирны җиңүгә Лада исемле дөясе алып килде. Ул 2 км араны 4 минут та 5 секунд эчендә үтте. Җиңүчегә бүләккә 200 мең сум акча бирелде.

Сабан туеның иң мавыктыргыч ярышы – ат чабышлары да булды. Быел ат чабышында Әстерхан өлкәсенең төрле төбәкләреннән 10 катнашучы көч сынашты. Борис Ванджаев һәм аның Сунхар исемле аты беренче урынны яулады. Ат 2 чакрым дистанцияне 2 минут та 54 секунд вакыт эчендә үтте. Җиңүчегә Әстерхан губернаторы Игорь Бабушкин «Лада Гранта» автомобиленең ачкычын тапшырды.

Бөтенроссия авыл Сабан туе кысасында авыл хуҗалыгы хайваннары һәм техника күргәзмәсе дә узды. Әстерхан төбәкләреннән 20дән артык фермер хуҗалыгы иң яхшы үгез, атларны, дөяләрне, сарыкларны, кәҗәләрне һәм төрле токымлы кошларны тәкъдим итте.

«Бу – минем 38 нче машинам»

Җыр-бию яратучылар сәхнә тирәсендә булса, спорт яратучылар көрәш мәйданында иде. Кайсылары концерт караган, кайсылары тәм-томнардан авыз иткән арада, мәйданда батырлар бил алышты. Көне дә, көрәше дә кызу булды. Баш батыр исеме өчен 100 килограммнан югарырак авырлык үлчәвендәгеләр генә көрәште. Төп приз өчен исә Татарстанның ике батыры: Раил Нургалиев белән Муса Галләмов бил алышты. Раил, Мусаны отып, абсолют батыр булып калды. Көрәшчегә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов бүләге – «Лада Гранта» автомобилен тапшырдылар. Раил Нургалиев көрәш ярышыннан соң хис-кичерешләре белән уртаклашты:

– Көрәшкә төрле төбәкләрдән: Әстерхан, Краснодар, Молдова, Татарстаннан бик күп егетләребез килде. Бик көчле көрәш булды. Монда Татарстаныбызның иң алдынгы егетләре җыелган иде. Җиңүче булып калдым, Аллага шөкер. Мин бик бәхетле. Бу – минем 38 нче машинам, – диде көрәшче.

Әстерхан халкы мондый зур милли бәйрәмгә сусаган булган. (Моңа кадәр бирегә ике тапкыр – 2008 һәм 2017 елларда федераль Сабан туе үткән иде.) Мәйдан бер секундка да тынмады, җыр-биюләр өзелмәде, бәйрәм рухы һәм кәефе һәр тарафта сизелеп торды. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезнең татарлыкны, гореф-гадәтләрне, бәйрәмне онытмавын, аларны хөрмәт итүен һәм яшь буынга тапшыруын күреп сокланып кайттык.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 275

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булараk тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерeп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәширият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+